СОВЕТ НУРИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ НӨНӘГӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ
28 июль 2021 ел

КАРАР
№ 29

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Советының 12.03.2021 елда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Ненәгәр авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 22нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Советының 12.03.2021 елда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Ненәгәр авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 22нче номерлы карарына (02.04.2021ел №24 үзгәрешләр белән) (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.Карарның атамасына «физик һәм юридик затлар милкендә булган җирләр " сүзләрен өстәргә»;

2.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

1) нигезләмәнең исемен «физик һәм юридик затлар милкендә булган җирләр»сүзләренә өстәргә;

2) пунктлар 2.2.2, 2.4, 3.3.1 – 3.3.7, 3.5, 3.14, 3.16,3.17 һәм 3.18 төшереп калдырырга;

3) 2.3 пунктта «милекчеләр» сүзен төшереп калдырырга;

4) 3.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Агач һәм куаклар кисүгә, кронлауга һәм утыртуга рөхсәт гариза бирү көнен дә кертеп, 13 кен эчендә бирелә.»;

5) 3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Рехсәт бирү гариза бирүченең Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиеш салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычы булмаганда, (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш) башкарыла.»;

6) 3.11 пунктында «рөхсәт ителергә мөмкин» сүзләрен «рехсәт ителә»сүзенә алмаштырырга.

7) 3.13 пунктта « № 2 кушымта нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 1 һәм № 2 кушымталарны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru),Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Нөнәгәр авыл җирлеге башлыгы А. З. Әхмәтханов